БАЛА ХОКУКЛАРЫ ТУРЫНДА КОНВЕНЦИЯ

Балалар хокуклары турында конвенция

- Берләштерелгән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясы тарафыннан 1989 елның 20 ноябрендә кабул ителде.
- 1990 елның 2 сентябрендә гамәлгә кертелде.
- Россиядә Конвенция 1990 елның 20 сентябрендә гамәлгә кертелде.

Конвенция ни өчен кирәк булды соң?

- Балалар яклауга мохтаҗ.
- Балалар дәүләт һәм әти-әни тарафыннан сакланырга тиеш.
- Балалар мәҗбүри эшләтелергә яки җәберләнергә мөмкин.
- Балаларның тавыш бирү хокукы юк, күп вакыт аларның тавышы ишетелмичә кала.

Нәкъ менә шуның өчен
Җирдә балаларның хокукын яклау кирәк.


Конвенциянең дүрт принципы
Дискриминацияне тыю
статья 2
Баланың карашлары
статья 12
Баланың мәнфәгатьләрен тәэмин итү
статья 3
Яшәүгә хокукы
статья 6

Дискриминацияне тыю (статья 2)

Катнашучы дәүләтләр үз юрисдикциясе чикләрендәге һәр баланы нинди дә булса дискриминацияләүсез, расасына, тән тиресе төсенә, җенесенә, теленә, диненә бәйсез рәвештә бу Конвенциядә каралган барлык хокуклар белән тәэмин итәләр һәм баланы теләсә нинди дискриминацияләү яисә җәзалау формаларыннан яклауны тәэмин итү өчен барлык кирәкле чаралар күрәләр.

Баланың мәнфәгатьләрен яклау(статья 3)

Катнашучы дәүләтләр, баланың ата-аналары, опекуннары һәм закон буенча аның өчен җавап бирүче башка затлар хокукларын һәм бурычларын игътибарга алып, балага аның иминлеге өчен кирәкле яклауны һәм аның турында кайгыртуны тәэмин итүне үз өстенә алалар һәм, әлеге максаттан чыгып, барлык тиешле закон һәм административ чараларны кабул итәләр.

Яшәүгә хокукын тәэмин итү (статья 6)

Катнашучы дәүләтләр:

- баланың яшәүгә аерылгысыз хокукы булуын таныйлар.
- баланың исән калуын һәм сәламәт үсүен мөмкин кадәр максималь дәрәҗәдә тәэмин итәләр.

Баланың карашлары(статья 12)

- баланың карашларын формалаштыруга, сәләтле балага аңа кагылышлы барлык мәсьәләләр буенча бу карашларын иркенле рәвештә белдерү хокукын тәэмин итәләр.
- баланың карашларына, аның яшенә һәм җитлегүенә карап, тиешле игътибар бирелә.



ҺӘР БАЛА ХОКУКЛЫ:



статья 7

Туган вакытыннан исем алу һәм гражданлык алу хокукына, үз ата-анасын белү хокукына һәм аларның кайгыртуы хокукына ия.

статья 14

Катнашучы дәүләтләр баланың фикер, намус һәм дин ирегенә хокукын хөрмәт итәләр.

статья 15-16

Катнашучы дәүләтләр баланың ассоциацияләр ирегенә һәм җәмәгать җыелышлары ирегенә хокукын танийлар.

Шәхси тормышына, гаилә тормышына,торагы кагылгысызлыгына хокуклы.

статья 17

Баланың төрле милли һәм халыкара чыганаклар мәгълүматларына һәм материалларына, керә алуын тәэмин итәләр

статья 19

Дәүләт баланы физик яисә психологик көчләүнең төрле формаларыннан, рәнҗетүдән, кимсетүле мөнәсәбәттә булудан яисә аны эксплуатацияләүдән яклау максаты өчен барлык кирәкле закон, административ, социаль һәм аң-белем бирү чаралары кабул итәләр.

статья 20

Гаиләсез калган балалар дәүләт тарафыннан якланырга, тиешле оешмаларга урнаштырылырга яисә тәрбияләү өчен аның милләтен, телен хөрмәт итүче гаиләгә бирелергә тиеш.

статья 24

Һәр бала сәламәтлек саклау системасының иң камил хезмәтләрен, авыруларны дәвалау һәм сәламәтлекне торгызу чараларын куллануга хокуклы.

статья 28

Балалар түләүсез башлангыч һәм урта белем алырга хокуклы.

статья 30

һәр бала үз динен тоту һәм үз гореф-гадәтләрен үтәү, шулай ук туган телдә сөйләшү хокукына ия.

статья 31

Катнашучы дәүләтләр баланың ял итүгә һәм күңел ачуга хокукын, уеннарда һәм күңел ачу чараларында катнашу һәм мәдәният тормышында иркле рәвештә катнашу хокукын таныйлар.

статья 32

Дәүләт баланың сәламәтлегенә һәм физик, акыл, мораль һәм социаль үсешенә зыян китергән теләсә нинди эшләр башкарудан яклауга хокукын таныйлар.

статья 33

Дәүләт балаларны наркотик яки башка психотроп матдәләр кулланудан һәм таратуда катнашудан сакларга тиеш.

статья 34

Дәүләт баланы җәзалау, урлау, законсыз ирегеннән мәхрүм итүгә юл куймауны тәэмин итә.

Ирегеннән мәхрүм ителгән бала гаиләсе белән аралашырга, суд тарафыннан якланырга хокуклы.

ИСЕГЕЗДӘ ТОТЫГЫЗ!!!
ХОКУКЛАРДАН КУЛЛАНЫГЫЗ,
ЛӘКИН БАШКАЛАРНЫҢ
ХОКУКЫН ДА ХӨРМӘТ ИТЕГЕЗ!!!